ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТЭН АВЫЛЫ СОВЕТЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
СОВЕТ ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423014, РТ, Нурлатский район, с. Гайтанкино, ул. Центральная, дом 1,
Тел. 8 (84345) 3-98-01

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«23» октябрь 2020 № 4

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кара Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы
КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 11 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Урман урамы 7нче йорт адресы буенча урнашкан ФАП бинасы янында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кара Күл авылында Урман урамы 1-32нче, Күл урамы 2-24нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә.

2. . Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Караи Күл территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

Авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән Кара Күл торак пунктында вак таш салу һәм сезонлы карап тоту

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/rus/nurlat_poselenia.htm, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кара Күл торак пунктының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева